

Шамиль Касыйм улы Баторшинга 65 яшь булуга карамастан, яшь күренә; ул шактый нык, тоз. Гомеренә, язмышына зарланмый. Ул бүгенге тормышыннан канәгать. Вакытынын күп олешен хужалык белән мәшгуль – тракторлар һәм автомобильләр ремонтлый, җәен - бакчада эшли, мал-туар карый, кышын - кар чистарта. Эш мәшәкатьләре дә аз түгел анын. Ял минутларында, күзлек киеп, газета-журналлар укый, кроссвордлар чишә, телевизор карый. Ирексездән бу хезмәт соючән кешегә, анын соялле кулларына карата хормәт һәм рәхмәтлелек хисе туа. Ул үз гомерендә туган колхозына, гаиләсенә, авылдашларына бик күп игелекле эшләр башкарды һәм дә кешеләргә бары тик яхшылыклар итүен дәвам итә.       Шамиль Касыйм улы Баторшин 1954нче елда Инсар районы Потиж елгасы ярына урнашкан Яндовище авылында туа. 1962нче елда жирле мәктәпкә укырга керә. 1967нче елнын җәендә беренче хезмәт күнекмәләрен ала: басуларында тормалы ат белән эшли башлый. Әмма аны тракторлар кызыксындыра. Колхоз кырларында куәтле дизельләрнен ничек эшләвен күзәтүе ана ошый. Ә аннары трактор кабинасында тракторчынын техника белән житез идарә итүен күзәтеп тора. Шуннан яшь Шамильдә механизатор булу фикере туа. Әмма бу хыял тиз генә тормышка аша алмый. Мәктәп каникулларында Шамиль туган авылы басуларында трактор ярдәмчесе булып эшли, шул ук вакытта ана трактор белән мостәкыйль идарә итүне ышанып тапшыруларын котә. Ярый әле, колхоз механизаторлары егетнен техникада эшләргә омтылуын анлап карыйлар; ана механизаторлык һонәре нигезләрен үзләштерүдә булышалар. Шулай, 1970нче елда ул комбайнчы ярдәмчесе булып туган кырларында үскән иген унышын жыя башлый. Намус белән хезмәт итә. Киләсе елда, авыл егетенә 17 яшь тулганда, СК- 4 комбаинында мостәкыйль эшләп ала. 1972нче елда, колхоз кырларында унышлы эшләгәне очен, Шамиль Касыйм улы Баторшин Смоленск шәһәренә туристик путевка белән бүләкләнә. Ә аннары тырыш хезмәте очен ел саен путевкалар алып, СССРнын күп кенә шәһәрләрендә була.
Язма героебыз чын-чынлап 1973нче елдан тракторда эшли башлый: башта МТЗ-82, аннары Т-150. Нәтижәле хезмәте, беренче чиратта, механизаторга үзенә бәйле. Техниканы тәртиптә тоту, ватылса, тиз арада ремонтлау, эшне оператив һәм сыйфатлы итеп башкару ягыннан Шамиль – һәрвакыт беренче. Алдынгы механизатор исеме юкка бирелми үзенә. Үз эшенен остасы булган егетебезнен эшеннән житәкчеләре бик тә канәгать булалар. Яшь егетнен техникага тартылуын күреп, колхоз житәкчелеге ана катлаулы биремнәрнен үтәлешен ышанып тапшыра. Мәсәлән, 1975нче елда Шамиль Касыйм улы Баторшин ярышларда тәжрибәлерәк тракторчыларны узып, колхоз

механизаторлары арасында беренче урынны яулый. Бу зур хезмәт жинvе ана гомер буена истә кала.
Аннары, 1997нче елда, Ш.К.Баторшин К-701 куәтле тракторында эшли. Бераздан янә МТЗ-82гә кvчә. Техниканын теләсә кайсысына утырса да - булдыра. Тормышын туган жиренә багышлаган чын авыл кешесе ул!
Бай механизаторлык тәжрибәсе булган Касыйм улы Шамильгә, 1982нче елдан алып, торле йок автомо-бильләрендә дә эшләргә туры килә: ГАЗ-51, ГАЗ-53, ЗИЛ-157. Колхозда шофер хезмәтен жинел дип әйтеп булмый. Бу елларда асфальт юллар юк диярлек. Жәй коне яуган янгырлардан сонгы пычракта һәм юлсызлыкта рейска чыгулар, кышын - кар кортләрен жинә-жинә йорvләр – барысын да жинә белде ул. Автомобилен һәрвакыт тозек хәлдә тотканга унышларга ирешә, шул. Хезмәт соючәнлеге һәм тырышлыгы очен аны «Федосеенко» исемендәге колхозда хормәт итәләр. Нинди эш йокләсәләр дә, нинди генә техникага утыртсалар да – барысын жиренә житкереп башкара, матур нәтижәләргә ирешә: 2008нче елда бензовозда эшләгәндә дә шулай була, 2013нче елда машина белән сыер савучыларны саварга йорткәндә дә. Анын тырыш хезмәт юлы еллары әнә шулай vткән. Намуслы хезмәте очен ул кvпсанлы бvләкләр белән дә бvләкләнгән.
Ул – чын авыл кешесе! Тормышын туган жиренә багышлаган кеше. Шамиль Касыйм улы vз гомерендә зур һәм янгыравыклы батырлык кылмаса да, әмма авылдагы озак еллар тырыш хезмәте батырлык тvгелмени? Бу тыйнак батырлык, әмма аны башкарган кеше шулай ук хормәткә һәм ихтирамга лаек. Гомер-гомергә авыл анын кебек тырыш хезмәткәрләр булышлыгы аркасында яши дә. Шамиль Касыйм улы Баторшинны туган авылы Яндовищесында гына белсәләр дә, бу анын хормәтен киметми һәм ул нәкъ менә хезмәте белән матур һәм данлы. Анын тормыш соючәнлеге һәм хезмәткә гадел каравы конләшерлек.

**Наилә Насырова**